# КАРАР

**2022 елның 31 октябре** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Сәрдек авылында гражданнар җыенына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегендә Яңа Сәрдек авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 31 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Сәрдек авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

тугызынчы абзацны киләсе редакциядә бәян итәргә:

"- су башнясын ремонтлау, карап тоту , сатып алу һәм урнаштыру, Яңа Сәрдек авылында артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 192 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 100

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 100 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Яңа Сәрдек авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021

елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Сәрдек авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

тугызынчы абзацны киләсе редакциядә бәян итергә:

"- су башнясын ремонтлау, карап тоту , сатып алу һәм урнаштыру, Яңа Сәрдек авылында артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сәрдекбаш авыл
җирлеге башлыгы И.М.Нәбиев